СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

26.10.2023 с. Набережные Моркваши 39-236

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 04.08.2023 ел N 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы 16.09. 2021 ел №11-78 Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 39 статьясындагы 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Нигезләмәнең 40 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме авыл җирлегенең Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс һәм икътисадый мәсьәләләр буенча Яр буе Морквашы авыл җирлегенең даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______________ И.Х.Гаязов